Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.11.2022 Менделеевск ш. №820

Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Урынны торак бина, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм реконструкцияләнергә яисә сүтелергә тиешле авария хәлендәге һәм торак йортны бакча йорты, бакча йортынторак йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 2 июлендәге 504 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2 бүлегенең 2.8 пунктындагы 2.8.2 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) су басу, су астынды калу зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гариза каралганда).»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Муниципаль хезмәтләр» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык буенча беренче урынбасары А.Ф. Искаковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров